ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ________________ КАРАР ________________

с. Верхний Услон

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48,

Иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы Министрлыгының иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру турында 09.09.2026 ел № 15-УРВИ-0011/2026 мөрәҗәгате нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы (Татарстан), Югары Ослан муниципаль районы, Югары Ослан авыл җирлеге, Түбән Ослан авыл җирлеге, Түбән Ослан авылы, Завод ур., 41 а з/у - адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:15:000000:2596, мәйданы 1637 кв. м. булган җир кишәрлегенең «кунакханә хезмәте»нә рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Түбән Ослан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1) Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының боерыгы проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләргә.

Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга - Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә проект буенча фикер алышуларны закон нигезендә оештырырга һәм үткәрергә.

2. Билгеләргә:

- проект буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыруның иң чик вакыты - 05.10.2026 ел;

3. «Мнение» мәгълүмат системасында экспозиция ачылачак (алга таба – «Мнение» МС), аны кулланып, https://mnenie.tatar.ru/ адресы буенча 21.09.2026 елдан 05.10.2026 елга кадәр иҗтимагый фикер алышулар үткәреләчәк.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: https://pravo.tatarstan.ru һәм Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге сайтында: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru 2026 елның 14 сентябрендә бастырып чыгарырга.

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе А.А. Ахметшин